КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО СОЦИАЛЬНО-ЭКОНОМИЧЕСКОМУ МОНИТОРИНГУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ - ИКЪТИСАДЫЙ МОНИТОРИНГ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.01.2015 **Казан шәһәре** 4-ОС

**Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында биләүләре коррупция куркынычына бәйле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Президентының 30.09.2010 № ПУ-636 Указы нигезендә **б о е р ы к б и р ә м**:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында (алга таба – Комитет) биләүләре коррупция куркынычына бәйле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.
2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы (В.Т. Сарипова) Комитетның Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен боерык белән таныштырырга тиеш.
3. Юридик секторның 2 категория белгече (Ю.Ф. Иксанова) боерыкны Комитетның рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга тиеш.
4. Әлеге борыкны үтәүне тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары О.Ю. Семенова

*Кушымта*

Татарстан Республикасының
Социаль-икътисадый
мониторинг комитетының
2015 елның 01 № 4-ос
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында биләүләре коррупция куркынычына бәйле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| N т/с | **Вазыйфа исеме** |
|---|---|
| | **Җитәкчелек** |
| 1. | Рәис урынбасары |
| | **Муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең хәлен социаль-икътисадый мониторинглау бүлеге** |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Бүлек башлыгы урынбасары |
| | **Мәгълүмат-аналитика бүлеге** |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Бүлек башлыгы урынбасары |
| | **Күрсәткечләрнең һәм мәгълүмат ресурсларының региональ базалары бүлеге** |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| | **Финанс һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге** |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының әйдәүче киңәшчесе |
| 3. | Финанс-икътисад секторының 1 нче разрядлы өлкән белгече (*контракт идарәчесе)* |
| | **Юридик сектор** |
| 1. | Сектор мөдире |